

Хәзерге көндә бакчабызда ике балалары (Хәйдәр һәм Мәрьям) тәрбияләнүче Зариповлар гаиләсен чын мәгънәсендә спорт яратучы гаилә дип атарга була. Гаилэд алты кеше: гаилә башлыгы Рифат, тормыш иптәше Роза,уллары Якуб,Салих,Хәйдәр һәм кызлары Мәрьям.Рифат малайларны көчле рухлы һәм нык тәнле итеп үстерү өчен кечкенәдән үк үзе белән карате-кекусинкай түгәрәгенә йөртә башлый. Әтиләренең тырышлыгы бушка китми-малайлар каратэда яхшы курсәткечләргә ия булалар. Район хәбәрчеләребез дә Якуб белән Салихның уңышлары турында газетабызда даими язып торалар.Үз яшьтәшләре арасындагы ярышларда «тукмашып» Якуб та,Салих та Марий Эл республикасында Кумитә өлкәсендә оештырылган чемпионатта 2че урынны алдылар (10.03.2013) Шулай ук Якуб каратэ кекусинкай (ката) буенча оештырылган Ботенрәсәй чемпионатында беренчелекне яулады (5.07.2013), Салих исә Казан шәһәренең ката буенча оештырылган ярышларында беренчелекне башкаларга бирмәде (20.01.13, 17.11.13). Каратэ белән генә чикләнми Зариповлар гаиләсе. Кышын бергәләп чангыда чыгалар, шугалакка йөриләр,җәен Каракулдә су коеналар.Аларга ныклы сәләмәтлек, спорт өлкэсендә алдагы ярышларда да зур унышлар теләп калабыз.